ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 565 2017 елның 6 сентябре

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 12 маендагы 319 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» Дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» Дәүләт программасының «2014-2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» ярдәмче программасы, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 декабрендә кабул ителгән 1740 номерлы карары белән расланган «2017-2020 елларга «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм һәм аны үстерү» муниципаль программасы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе турында» (алга таба – Тәртип) 2017 елның 12 маендагы 319 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 7.2.1 пунктының «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «эшкуарлык субъектларына финанс арендасына (лизингка) мөлкәт бирү өлкәсендә өч елдан да ким булмаган эш тәҗрибәсе булу, яисә соңгы хисап датасына устав капиталының күләме - 2 млрд сумнан да ким булмаган күләмдә булу;».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И. Беляевка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов